125. Гражданнар сугышы вакыйгалары һәм аларның булу вакыты арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| ВАКЫЙГАЛАР | ЕЛЛАР |
|---|---|
| А) П.Н. Врангель гаскәрләрен тар-мар итү | 1) 1918 ел |
| Б) А.В. Колчак гаскәрләрен тар-мар итү | 2) 1919 ел |
| В) Чехословакия корпусы восстаниесе башлану | 3) 1920 ел |
| | 4) 1921 ел |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

126. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы иң ахырда булган?

**1)** продразвёрстка кертү

**2)** СССРның беренче Конституциясен кабул итү

**3)** Брест Солыхы төзү

**4)** Учредительный собраниене тарату

127. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы яңа икътисад сәясәте (нэп) чорында булган?

**1)** стахановчылык хәрәкәте

**2)** азык-төлек диктатурасы

**3)** хезмәт өчен тигез түләү

**4)** хезмәт биржалары

128. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы иң ахырда булган?


**1)** А.В. Колчакны Россиянең Югары дәүләт башлыгы дип белдерү

**2)** Кырымда П.Н. Врангель армиясен тар-мар итү

**3)** РСФСРның беренче Конституциясен төзү

**4)** А.И. Деникин армиясенең Мәскәүгә һөҗүме

129. Рәсемне карагыз.



Әлеге плакат СССРда ничәнче елда булган вакыйга уңае белән ясалган?

1) 1956 ел

2) 1974 ел

3) 1980 ел

4) 1985 ел

130. И.В. Сталин үлгәннән соң хакимлек өчен көрәштә кемнәр катнашкан?


1) Н.И. Бухарин һәм А.И. Рыков

2) С.М. Киров һәм Г.К. Орджоникидзе

3) Н.С. Хрущёв һәм Л.П. Берия

4) Л.И. Брежнев һәм А.Н. Косыгин

131. Рәсемне карагыз һәм биремне үтәгез.



Әлеге плакатның ничәнче елда ясалуын күрсәтегез.

1) 1917 елда
2) 1918 елда
3) 1919 елда
4) 1920 елда

132. Түбәндә саналып киткән шәхесләрнең кайсысы 1930 елда сәяси суд процессларының берсендә гаепләнүче булган?

1) С.М. Киров
2) М.Н. Тухачевский
3) Ф.Э. Дзержинский
4) В.М. Молотов

133. Җир турында Декрет кайчан кабул ителгән?

1) 1917 елда
2) 1921 елда
3) 1924 елда
4) 1929 елда

134. Генерал И.В. Панфилов җитәкчелегендәге 316 нчы укчылар дивизиясе нинди сугыш вакытында дан казанган?

1) Мәскәү өчен сугыш
2) Сталинград өчен сугыш
3) Курск сугышы
4) Белоруссияне азат итү операциясе

135. “Җепшеклек” чорында СССРда мәдәният үсешенең үзенчәлекле билгесен күрсәтегез.

1) дәүләт тарафыннан Рус Православие Чиркәвенә ярдәм күрсәтелү
2) мәдәнияттә бердәм рәсми юнәлеш булу - соцреализм

**3)** мәдәният эшлеклеләренә карата эзәрлекләү һәм тәнкыйть булмау

**4)** дәүләт башлыкларының автобиографик әсәрләрен бастырып чыгару

136. «Салкын сугыш»ның башлануы кайсы елларга карый?

**1)** 1940 елларның икенче яртысына

**2)** 1950 елларның беренче яртысына

**3)** 1950 елларның икенче яртысына

**4)** 1960 елларның беренче яртысына

137. И.В. Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсендә нинди фикер әйтелә?

**1)** күмәкләштерү темпларын тизләтергә

**2)** авыл ресурслары хисабына индустрияләштерү үткәрмәскә

**3)** бишьеллыкны дүрт елда башкарып чыгарга

**4)** колхозларны мәҗбүри кертмәскә

138. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.



1968 елда Варшава килешүе оешмасында катнашкан илләрнең гаскәрләре кертелгән ил нинди цифр белән билгеләнгән?

**1)** 1

**2)** 2

**3)** 3

**4)** 4

139. Гражданнар сугышы вакытында акларның һәм кызылларның сәяси үзенчәлекләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага – охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын языгыз.

**1)** алпавыт җирләрен законлы рәвештә крестьяннарныкы итү

**2)** халыкның аерым өлешенә террор оештыру

**3)** контроль астында булган территорияләрдә диктатура режимы кертү

**4)** сәнәгнать предприятияләрен законлы рәвештә национализацияләү

140. Гражданнар сугышы вакытында крестьяннар арасында баш күтәрүчеләрнең җитәкчеләренең берсен күрсәтегез.

**1)** С.М. Будённый

**2)** Н.И. Махно

**3)** М.В. Фрунзе

**4)** М.Н. Тухачевский

141. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы 1917 елның февралендәге революцион вакыйгаларның бер нәтиҗәсе булган?

**1)** Россиянең Беренче бөтендөнья сугышыннан чыгуы

**2)** Николай II тарафыннан ваз кичү турында манифестка кул куелу

**3)** алпавыт җирбиләүчелеген бетерү

**4)** Совет власте урнашу

142. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы 1920 – 1930 еллар ахырында СССРда индустрияләштерү үткәрү өчен сәбәп булган?

1) көнбатыш илләре белән сәүдә мөнәсәбәтләрен җайга салырга тырышу

2) җиңел сәнәгатьнең тиз үсеше өчен шартлар тудыру

3) совет җитәкчелегенең базар икътисадына күчү зарурлыгын аңлавы

4) совет җитәкчелегенең СССРның икътисади яктан бәйсезлеген тәэмин итәргә омтылуы

143. Кызылларның һәм акларның Россиянең Европа өлешендәге көрәше ничәнче елда Кырымда П.Н. Врангель гаскәләрен тар-мар итү белән тәгәлләнгән?

1) 1915 елда

2) 1918 елда

3) 1920 елда

4) 1924 елда

144. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы иң ахырда булган?

1) Россиянең Беренче Бөтендөнья сугышына керүе

2) Николай II нең патша булуы

3) Беренче Россия революциясе башлану

4) Учредительный собрание таратылу

145. Халык Комиссарлары Советы ничәнче елда төзелгән?

1) 1914 елда

2) 1917 елда

3) 1922 елда

4) 1936 елда

147. Николай II тәхеттән ваз кичү турында манифестка кайчан кул куйган?

1) 1905 елның 17 октябрендә
2) 1917 елның 2 мартында
3) 1917 елның 25 октябрендә
4) 1918 елның 5 январендә

148. СССР Конституциясен кабул итү белән бәйле еллар кайсы рәттә бирелгән?

1) 1924 ел, 1936 ел
2) 1927 ел, 1939 ел
3) 1928 ел, 1940 ел
4) 1930 ел, 1938 ел

149. Кызыл Армияне гомуми хәрби йөкләмә нигезендә формалаштыруга күчү ничәнче елда тормышка ашырыла башлаган?

1) 1917 елда
2) 1918 елда
3) 1920 елда
4) 1924 елда

150. Советларның IV Бөтенроссия съезды РСФСРның Германия һәм аның союздашлары белән солых килешүен ничәнче елда раслаган?

1) 1917 елда
2) 1918 елда
3) 1919 елда
4) 1920 елда

151. “Хәрби коммунизм” сәясәтеннән яңа икътисад сәястенә (нэп) күчү турында карар ничәнче елда кабул ителгән?

1) 1918 елда

**2)** 1921 елда

**3)** 1929 елда

**4)** 1934 елда

152. СССР белән Финляндия арасында сугыш кайчан булган?

**1)** 1924— 1930 елларда

**2)** 1925— 1927 елларда

**3)** 1936— 1939 елларда

**4)** 1939— 1940 елларда

153. 1921 елда Совет дәүләте тарафыннан кертелгән крестьян хуҗалыкларыннан мәҗбүри натураль һәм акчалата түләтү ничек дип аталган?

**1)** продразвёрстка

**2)** азык-төлек салымы

**3)** җан башыннан алына торган салым

**4)** акчалата җыем (пошлина)

154. Түбәндә санап кителгән республикаларның кайсысы СССР составына иң ахырда кергән?

**1)** Украина ССР

**2)** РСФСР

**3)** Белорусия ССР

**4)** Литва ССР

155. Түбәндә санап кителгән төшенчәләрнең кайсысы яңа икътисад сәясәте (нэп) белән бәйле (1921–1929 гг.)?

**1)** гомуми хезмәт йөкләмәсе

**2)** стахановчы

**3)** капиталга «кызыл Гвардеец атакасы»

**4)** концессия

156. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы Россиядә Гражданнар сугышы вакытында булган?

**1)** Брусилов өзеклеге

**2)** Мукден бәрелеше

**3)** Портсмут Солыхына кул куелу

**4)** Н.Н. Юденич армиясенең Петроградка походы

157. Түбәндә санап кителгән төшенчәләрнең кайсысы 1917 елгы революция вакыйгалары барышында барлыкка килгән?

**1)** сарай борылышы

**2)** ике хакимиятлелек

**3)** сәнәгать борылышы

**4)** конституцион монархия

158. 1918 елда большевиклар тарафыннан таратылган сайланып куела торган хакимият органы ничек дип аталган?

**1)** Бөтенроссия Советлар съезды

**2)** Петроград Советы

**3)** Халык Комиссарлары Советы

**4)** Учредительное собрание

159. Индустрияләштерү сәясәте үткәрү нәтиҗәсендә ...

**1)** СССР кеше башына продукция җитештерү буенча дөньяда беренче урынга чыккан

**2)** бәяләргә контроль кимегән

**3)** сәнәгать җайланмаларына импорт кимегән

**4)** илгә чит ил капиталы кертү арткан

160. “Тормыш юлы” атамасы Бөек Ватан сугышы вакытында кайсы шәһәрне азат итү белән бәйле?

1) Мәскәү
2) Севастополь
3) Ленинград
4) Одесса

161. Бөек ватан сугышы барышында тамырдан борылыш фашист гаскәрләре кайда тар-мар ителгәннән соң ирешелгән?

1) Мәскәү янында
2) Сталинград янында һәм Курск дугасында
3) Көнчыгыш Пруссиядә
4) Белоруссиядә

162. Совет гаскәрләренең Сталинград янындагы контрһөҗүме кайчан башланган?

1) 1941 елның 5 декабрендә
2) 1942 елның 19 ноябрендә
3) 1943 елның 5 июлендә
4) 1944 елның 6 июнендә

163. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1943 елда булган?

1) Мәскәү өчен сугыш
2) Белоруссияне азат итү
3) Ленинград блокадасын өзү
4) Курск сугышы

164. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1944 елда булган?

1) Смоленск сугышы
2) Мәскәү өчен сугыш
3) Ленинград блокадасын тулысынча өзү

**4)** Курск сугышы

165. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы Бөек ватан сугышы барышында тамырдан борылышка китерә?

**1)** Мәскәү өчен сугыш

**2)** Сталинград сугышы

**3)** Висло-Одер операциясе

**4)** Берлин операциясе

166. Берлин өчен сугышта совет гаскәрләре ...

**1)** Одер елгасына чыктылар

**2)** Көнчыгыш Европа илләрен азат итә башлау өчен шартлар тудырдылар

**3)** Германия союзниклары рәтендә таркаулык барлыкка китерделәр

**4)** Эльба елгасына чыктылар

167. Тарихи чыганактан өзек укыгыз һәм аның язылу вакытын күрсәтегез.
«Фашизм урта гасыр варварлары кебек кыланып, канлы итеге белән Европа илләрен сытты, халыкларын фәкыйрьлеккә һәм ачлыкка дучар итте, хәзер Советлар Союзына һөҗүм итте.
Тынычлык өчен тавыш биргән халыклар хәзер сугышырга тиеш...
Җиңүебезгә, гаделлек тантанасына бер дә шикләнмичә, кызыл йолдыз астында берләшик һәм Советлар Союзы өчен көрәшкә күтәрелик!»

**1)** 1939 елның көзендә

**2)** 1940 елның көзендә

**3)** 1941 елның язында

**4)** 1941 елның җәендә

168. Шул заманда яшәгән бер хатын-кызның көндәлегеннән өзек укыгыз һәм текстта ике тапкыр төшеп калдырылган тарихи эшлекленең фамилиясен күрсәтегез.
«Бүген Куйбышевларда кундык. Иртән өйгә кайтып китәргә җыенганда мөһим хәбәр ишеттек: “ 12.15. _____________ чыгыш ясаячак”. Нәрсә булды икән? Без төрлечә фаразлап карадык, ләкин, әлбәттә, берничек тә дөрес сәбәпне уйлап таба алмадык.

Сугыш! Германия, сатлык җаннар кебек, вәхшиләрчә, безнең илгә һөҗүм иткән. Киев, Житомир, Брестка бомба яудырган. Немецлар чикне үтеп чыкканнар. ___________ның ялкынлы чыгышы бер генә теләк тудырды – фронтка китәргә, гомуми эшкә үз өлешемне кертергә, дошманнарны тар-мар итәргә. Иртәгә үк Кызыл Хаҗ район бүлегенә (РОКК) керергә һәм дружинага язылырга карар кылдым.”

1) С.М. Будённый
2) Л.Д. Троцкий
3) С.М. Киров
4) В.М. Молотов

169. Бөек Ватан сугышында катнашучының истәлекләреннән өзек укыгыз һәм кайсы шәһәр турында сүз баруын әйтегез.

«Салкыннар шәһәргә бернәрсә белән дә чагыштырып булмый торган югалтулар алып килде. Азык-төлек запаслары шулкадәр кимеде ки, хәтта кайсы көннәрдә аларны бирү туктатылды.

Йөз меңнәрчә үлүчеләрнең күпчелеге беренче ач кышка туры килде...

Ләкин шәһәрдә, блокада булуга карамастан, тормыш туктамады. Көндез ул боз чүлен хәтерләтте: берничә квартал үтеп тә, беркем дә очрамаска мөмкин иде. Шулай да һәр көннең иртәсендә үзәк урамнар буйлап, бигрәк тә завод районнарына алып бара торган юллардан, кешеләр агылды. Бу агымга хәрәкәтләнә алган теләсә кем кушыла иде. Фронт өзлексез рәвештә блокадалы шәһәрдә яшәүчеләр ясаган патроннар, корал, снарядлар алып торды».

1) Сталинград
2) Мәскәү
3) Киев
4) Ленинград

170. Истәлекләрдән өзек укыгыз һәм текстта тасвирланган сугышта катнашкан совет хәрби башлыгын күрсәтегез.

«Сталинград утта иде. Янгын уты берничә йөз метрга күтәрелде. Фашист самолетлары баш өстеннән очып үттеләр. Төтен һәм тузан болытлары күзләрне

кисте, биналар җимерелде, стеналар ауды, тимер эреде. Бөтен тереклек үлә кебек иде, ләкин кешеләр сугышка бардылар. Мамай курганында да кызу булды. Көн дәвамында фашистлар алты тапкыр югарыдан безнең подразделениеләрне юкка чыгарырга теләделәр, ләкин һәрберсендә кире кагылдылар. Гвардеецлар дошманның бөтен һөҗүменә каршы тордылар».

1) Л.М. Доватор
2) В.И. Чуйков
3) Д.Г. Павлов
4) И.В. Панфилов

171. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1970 елларда булган?

1) Корея сугышы тәмамлану
2) совет гаскәрләрен Афганистаннан чыгару
3) Икътисади ярдәмләшү советын (СЭВ) тарату
4) Европада Куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек буенча киңәшмә үткәрү

172. Н.С. Хрущёв ничәнче елларда КПСС ҮК беренче секретаре булган?

1) 1945— 1953 елларда
2) 1953— 1964 елларда
3) 1965— 1985 елларда
4) 1985— 1991 елларда

173. Ничәнче елда РСФСР Президентын сайлау булган?

1) 1985 елда
2) 1989 елда
3) 1991 елда
4) 1993 елда

174. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы XXI гасыр башына карый?

1) ирекле бәяләргә күчү

2) приоритетлы милли проектларны тормышка ашыру

3) ваучер хосусыйлаштыруы

4) күп партиялелек системасына күчү

175. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1985 елга карый?

1) И.В. Сталинның шәхес культын фаш итә башлау

2) социаль-икътисади үсешне тизләтү курсына күчүне игълан итү

3) Бәйсез Дәүләтләр бердәмлеге (СНГ) барлыкка килү

4) СССР Конституциясе кабул ителү

176. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1970 елда булган?

1) И.В. Сталинның шәхес культын фаш итә башлау

2) СССР Президентын сайлау

3) СССР Конституциясе кабул ителү

4) Халык депутатлары съезды эшчәнлеге

177. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1980 елларның икенче яртысында булган?

1) совет гаскәрләрен Афганистаннан чыгару

2) Кариб кризисын җайга салу

3) Европада Куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек буенча киңәшмәнең Ахыргы актына кул куелу

4) Берлин стенасын торгызу

178. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1940 елларның икенче яртысында – 1950 елларда булган?

1) Берлин стенасын торгызу

2) СССР җитәкчелеге тарафыннан “яңача фикерләү концепция”сен алга чыгару

3) НАТО һәм Варшава килешүе оешмасы (ОВД) хәрби-сәяси блокларның формалашуы

4) Атмосферада, космик киңлектә һәм су астында атом-төш коралларын сынауны тыю турында килешүгә кул куелу

179. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1962 елда булган?

1) чирәм җирләрне массакүләм үзләштерә башлау

2) КПССның XX съезды

3) Кариб кризисы

4) СССР җитәкчесенең АКШка беренче визиты

180. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1940 елларның ахырында булган?

1) Варшава килешүе оешмасы (ОВД) гаскәрләрен Чехословакиягә кертү

2) Икътисади ярдәмләшү советы (СЭВ) төзелү

3) Кариб кризисы

4) Милли Лига төзелү

181. 2000 елда нинди вакыйга булган?

1) «500 көн» программасы төзелү

2) РСФСРның Халык депутатлары съезды оешу

3) Россиядә федераль төбәкләр барлыкка килү

4) РФ Конституциясе кабул ителү

182. СССР бетү һәм СНГ төзелү турында Беловеж килешүенә кайчан кул куелган?

1) 1990 елның июнендә

2) 1991 елның мартында

3) 1991 елның декабрендә

4) 1993 елның октябрендә

183. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы 1960 елларга туры килә?

**1)** Сталинчылыкка каршы сәясәт башлану

**2)** сәнәгать белән идарә итүнең тармак системасы тергезелү

**3)** хәбәрдарлык сәясәтенә күчү

**4)** “яңача фикерләү концепция”се алга чыгу

184.  Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XXI гасыр башында булган?

**1)** Россиянең Европа Советына керүе

**2)** РФ Конституциясе кабул ителү

**3)** РФ Иҗтимагый палатасы төзелү

**4)** Федератив килешүгә кул куелу

186. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1945— 1953 еллар аралыгында булган?

**1)** РФ Конституциясе кабул ителү

**2)** карта системасы бетерелү

**3)** диссидентлык хәрәкәте барлыкка килү

**4)** «Шәхси хезмәт эшчәнлеге турында» Закон кабул ителү

187. Түбәндә санап кителгән чорларның кайсысы СССРда “үзгәртеп кору” чоры дип атала?

**1)** 1953— 1964 еллар

**2)** 1965— 1985 еллар

**3)** 1985— 1991 еллар

**4)** 1992— 1999 еллар

188. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1940 еллар ахырында булган?

**1)** Кариб кризисы

**2)** совет гаскәрләрен Афганистаннан чыгару

**3)** Варшава килешүе оешмасы төзелү

**4)** Икътисади ярдәмләшү советы (СЭВ) төзелү

189. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1988 елда булган?

**1)** КПССның XIX конференциясендә “Совет җәмгыятен демократлаштыру һәм сәяси системаның реформалары турында” резолюция кабул ителү

**2)** СССР халык депутатларының I Съезды

**3)** Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге (СНГ) төзү турында Беловеж килешүенә кул куелу

**4)** КПССның XXII съездында СССРда коммунизм төзү турында Программа кабул ителү

190. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1980—1990 еллар чигендә «суверенитетлар парады» атамасын алган?

**1)** өч совет республикасы лидерлары тарафыннан Беловеж килешүенә кул куелу

**2)** М.С. Горбачёвның отставкага китүе һәм СССР таркалу

**3)** яңа Союз килешүен тикшерү

**4)** республикаларның союз үзәгеннән бәйсез дип белдерүләре

191. Бөек Ватан сугышыннан соң сәнәгатьне тиз арада тергезүнең бер чыганагы нәрсә булган?

**1)** халыкара банклардан кредитлар алу

**2)** Көнчыгыш Европа илләренең икътисади яктан ярдәм күрсәтүе

**3)** сәнәгатьнең авыл хуҗалыгына караганда күбрәк финанслануы

**4)** «Маршалл планы» буенча совет икътисадын финанслау

192. Көнбатыш илләрендә совет җитәкчелегенең “Брежнев доктринасы” дигән исем алган тышкы сәясәт курсы нәрсәне күздә тоткан?

**1)** стратегик кораллануны кыскарту

2) Варшава килешүе оешмасын тарату

3) регионнарда хәрби каршылыкларны бетерү

4) социалистик илләрнең бердәмлеген ныгыту

193. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы 1990 елларда Россиядә икътисади реформа рамкаларында үткәрелгән?

1) территориаль халык хуҗалыгы советлары (совнархоз) төзелү

2) фиксацияләнгән дәүләт бәяләре кертелү

3) предприятияләргә госприёмка кертелү

4) бәяләргә контроль кимү

194. 1950 елларның икенче яртысында СССРда фән-техника казанышлары беренче чиратта кайсы өлкәгә кертелгән?

1) хәрби-сәнәгать комплексына

2) авыл-хуҗалыгы җитештерүенә

3) транспортка

4) халык куллану товарларын җитештерүгә

195. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы СССРда "үзгәртеп кору" чорындагы икътисади үзгәрешләргә туры килә?

1) эре сәнәгать предпиятиеләрен национализацияләү

2) банкларны национализацияләү

3) колхоз һәм совхозларны эреләндерү

4) кооператив хәрәкәте үсешенә ярдәм итү

196. Россиянең хәзерге замандагы тышкы сәясәтенең бер юнәлеше булып тора:

1) халыкара терроризм белән көрәшү

2) Көнчыгыш Европа илләренең коммунистик партияләренә ярдәм күрсәтү

3) атмосферада, космик киңлектә һәм су астында атом-төш коралларын

сынауны тыю турында килешү әзерләү

4) «салкын сугыш»ны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү

197. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы СССРның “үзгәртеп кору” чорындагы социаль-икътисади үсешне тизләтүгә юнәлдерелгән курсын күздә тоткан?

1) базар икътисадына күчү

2) бәяләргә контроль кимү

3) фән-техника прогрессы үсү

4) дәүләт милкен хосусыйлаштыруны үткәрү

198. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы СССРда “җепшеклек” чорында булган?

1) Днепрогэсны тергезү тәмамлану

2) дәүләт милкен хосусыйлаштыра башлау

3) «Шәхси хезмәт эшчәнлеге турында» Закон кабул ителү

4) чирәм һәм яткын җирләрне массакүләм үзләштерә башлау

199. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы сугыштан соңгы елларда (1945—1950 еллар) СССРның халыкара хәлен характерлый?

1) халыкара киеренкелек басыла төшү

2) Көнбатыш илләре белән “салкын сугыш” башлану

3) Көнчыгыш Европа илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләрне өзү

4) АКШ һәм Бөекбритания белән союздашлык мөнәсәбәтләре ныгу

200. Түбәндә санап кителгән чараларның кайсысы СССРда сугыштан соңгы елларда (1945—1950 еллар) үткәрелгән?

1) территориаль халык хуҗалыгы советлары (совнархоз) төзелү

2) продразвёрстканы азык-төлек салымы белән алмаштыру

3) азык-төлек карточкаларын бетерү

4) колхозчыларга җирне арендага алу мөмкинлеген бирү

201. СССРда күп партиялелек нинди чорда барлыкка килгән?

1) беренче сугыштан соңгы уньеллык
2) «җепшеклек»
3) «торгынлык»
4) «үзгәртеп  кору»

202. 1990 елларда Россия кайсы халыкара оешманың әгъзасы булды?

1) Үзара икътисади ярдәмләшү советы
2) Европа Советы
3) Бөтендөнья сәүдә оешмасы
4) Европа парламенты

203. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы 1980 еллар ахыры—1990 еллар башында  «суверенитетлар парады» атамасын алган?

1) өч совет республикасы лидерлары тарафыннан Беловеж килешүенә кул куелу
2) Яңа Федератив килешүгә кул куелу
3) республикаларның союз үзәгеннән бәйсез дип белдерүләре
4) М.С. Горбачёвның отставкага китүе һәм СССР таркалу

204. СССРда Бөек Ватан сугышыннан соң халык хуҗалыгын тергезү елларында кайсы тармак калдыклык принципы буенча финансланган?

1) авыр сәнәгать  предприятиеләре
2) кораллы көчләр
3) атом-төш энергетикасы өлкәсендәге эшләр
4) җиңел һәм азык-төлек сәнәгате

205. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы СССРда 1960 елларның икенче

яртысындагы икътисади реформаны чагылдыра?

1) шәхси эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә рөхсәт ителү
2) оборона программаларын финанслауны туктату
3) сәнәгать предприятиеләрен хосусыйлаштыру
4) эшчеләрне икътисади яктан стимуллаштыру

206. СССРның яшәүдән туктавы һәм БДБ төзелү турында Беловеж килешүенә кайсы республикаларның җитәкчеләре тарафыннан кул куелган?

1) Россия, Белоруссия, Украина
2) Россия, Казахстан, Украина
3) элеккеге СССРның барлык республикалары
4) Балтыйк буе республикаларыннан кала элеккеге СССРның барлык республикалары

207. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы СССРда “үзгәртеп кору” чорында булган?

1) социалистик илләр белән хәрби-сәяси һәм икътисади хезмәттәшлекнең ныгуы
2) Совет гаскәрләрен Афганистаннан чыгару
3) СССР һәм АКШ арасында хәрби-стратегик паритетка ирешү
4) СССР җитәкчесенең АКШка беренче визиты

208. СССРның “торгынлык” чорындагы сәясәтен нәрсә характерлый?

1) сәяси реформалар актив үткәрелү
2) партия аппараты власте көчсезләнү
3) И.В. Сталинның шәхес культын тәнкыйтьләү кимү
4) диссидентлык хәрәкәте белән көрәшүдән баш тарту

209. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы 1990 елларда Россиянең иҗтимагый-

сәяси тормышы өчен яңа күренеш була?

1) социализмны яңарту курсына юл тоту
2) Халык депутатлары съезды чакырылу
3) РФ Президентын сайлау
4) бер партиялелек системасы урнашу

210. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы СССРда “үзгәртеп кору” чорындагы сәяси система реформасына туры килә?

1) СССР Президенты вазыйфасы барлыкка килү
2) СССР Министрлар Советы оешу
3) Дәүләт Думасы төзелү
4) СССРның яңа Конституциясе кабул ителү

211. Сәясәт эшлеклесенең докладыннан өзек укыгыз һәм бу докладның кайсы уньеллыкта ясалуын күрсәтегез.
«Әлеге докладта Сталинның тормышына һәм эшчәнлегенә төрле яклап бәя бирү максаты куелмый. Сталинның күрсәткән хезмәтләре турында ул әле исән чакта ук җитәрлек санда китаплар, брошюралар, тикшеренүләр язылган. Социалистик революцияне әзерләүдә һәм үткәрүдә, гражданнар сугышында, илебездә социализм төзү өчен көрштә Сталинның роле һәркемгә билгеле. Хәзер партиянең бүгенгесе һәм киләчәге өчен зур әһәмияткә ия булган мәсьәлә турында сүз бара, - сүз аерым этапта партия принципларын, партия демократиясен, революцион законлыкны әкренләп бозыклык чыганагына әйләндергән Сталинның шәхес культы урнашуы турында.”

1) 1940 елларда
2) 1950 елларда
3) 1960 елларда
4) 1970 елларда

212. Бөек Ватан сугышының күренекле полководецлары -

1) Г.К. Жуков, А.М. Василевский

2) М.Н. Тухачевский, М.В. Фрунзе

3) В.И. Чапаев, С.С. Каменев

4) А.А. Брусилов, Ф.Э. Дзержинский

213. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы 2000—2008 елларда В.В.Путинның РФ Президенты урынындагы эшчәнлеге белән бәйле?

1) РФ Дәүләт Думасы төзелү

2) Россия Федерациясенең Конституцион киңәшмәсе төзелү

3) Россиядә җиде федераль төбәк барлыкка килү

4) халык депутатлары Съезды чакырылу

214. Бөек Ватан сугышы вакытында зур  партизан берләшмәсенең командиры -

1) С.А. Ковпак

2) С.К. Тимошенко

3) Н.Ф. Гастелло

4) В.И. Чуйков

215. Түбәндә санап кителгән хәрби җитәкчеләрнең кайсысы Кызыл армия җитәкчесе булган?

1) А.И. Деникин

2) В.К. Блюхер

3) А.В. Колчак

4) Н.Н. Юденич

216. “Яңача сәяси фикерләү” концепциясе кем тарафыннан тәкъдим ителгән?

1) Н.С. Хрущёв

2) Л.И. Брежнев

3) Ю.В. Андропов

**4)** М.С. Горбачёв

217. “Алга киткән социализм” концепциясе СССРда кайсы җитәкче идарә иткән чорда тәкъдим ителгән?

**1)** Б.Н. Ельцин

**2)** Н.С. Хрущёв

**3)** Л.И. Брежнев

**4)** М.С. Горбачёв

218. СССРда күп партиялелек ил белән кем идарә иткән чорда барлыкка килгән?

**1)** Л.И. Брежнев

**2)** М.С. Горбачёв

**3)** Н.С. Хрущёв

**4)** И.В. Сталин

219. А.И. Солженицынны СССРдан куу кайсы чорга карый?

**1)** И.В. Сталинның ил белән идарә итүенең соңгы еллары

**2)** «җепшеклек»

**3)** «торгынлык»

**4)** «үзгәртеп кору»

220. 1920—1930 елларда совет хөкүмәтенең мәдәният өлкәсендәге сәясәте нәрсәне күздә тоткан?

**1)** элеккеге интеллигенцияне эмиграциядән кире кайтару

**2)** гимназиядә белем бирүне тергезү

**3)** сәнгатьтә төрле идеяле юнәлешләрнең үзара мөнәсәбәте

**4)** фән һәм мәгарифне идеологиягә кору

221. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы СССРда “җепшеклек” чорында булган?

**1)** А.И. Солженицынның “Иван Денисовичның бер көне” («Один день Ивана

Денисовича») повестен бастырып чыгару

**2)** «Взгляд», «До и после полуночи», «Пятое колесо», «600 секунд» дип аталган популяр публицистик һәм информацион телевизион тапшырулар барлыкка килү

**3)** ил экраннарына С.М. Эйзенштейнның «Броненосец "Потёмкин"» дип аталган фильмы чыгу

**4)** космополитизм белән көрәштә идеологик компания оештырылу

222. Түбәндә санап кителгән язучыларның кайсысы XX гасырның икенче яртысында Нобель премиясе лауреаты булган?

**1)** М.А. Шолохов

**2)** К.М. Симонов

**3)** А.Т. Твардовский

**4)** А.Н. Толстой

223. Түбәндә санап кителгәннәрнең кайсысы СССРның 1930 еллардагы мәдәният өлкәсендәге дәүләт сәясәтен характерлый?

**1)** мәдәниятнең  идеологик контрольдән азат булуы

**2)** цензураны бетерү

**3)** сәнгатьтә стильләрнең күплеген яклау

**4)** әдәбиятта һәм сәнгатьтә социалистик реализм методын раслау

224. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы XX гасырның икенче яртысында булган?

**1)** шартлы рефлекслар теориясе барлыкка килү

**2)** Мәскәү сәнгать театры төзелү

**3)** «Смена вех» җыентыгы басылу

**4)** космик киңлекне үзләштерә башлау

225. К.М. Симоновның «Жди меня», А.Т. Твардовскийның «Василий Тёркин», Б.Л.

Васильевның «А зори здесь тихие…» әсәрләре кайсы чорга багышланган?

1) Россиядә Гражданнар сугышына
2) 1930 елларда массакүләм репрессияләргә
3) Бөек Ватан сугышына
4) «җепшеклек» чорына

226. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсысы СССРның "җепшеклек" чорына карый?

1) «Ленин» дип аталган беренче атом бозваткычын суга төшерү
2) «челюскинчы»ларны коткару
3) «Мир» орбиталь космик станциясенең очуы
4) СССРда генетиканы һәм агробиологияне юкка чыгару

227. СССР катнашы белән үткәрелгән халыкара вакыйгалар һәм шул вакыйгалар булган еллар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **ВАКЫЙГАЛАР** | **ЕЛЛАР** |
|---|---|
| **А)** Потсдам конференциясе | **1)** 1945 ел |
| **Б)** Берлин стенасын күтәрү | **2)** 1949 ел |
| **В)** Үзара икътисади ярдәмләшү Советы төзелү | **3)** 1956 ел |
| | **4)** 1961 ел |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

228. Вакыйгалар һәм шул вакыйгалар булган еллар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **ВАКЫЙГАЛАР** | **ЕЛЛАР** |
|---|---|
| **А)** Н.С. Хрущёвны КПСС ҮК Беренче | **1)** 1953 ел |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | секретаре итеп сайлау | **2)** | 1961 ел |
| **Б)** | СССР таркалу | **3)** | 1965 ел |
| **В)** | А.Н. Косыгинның икътисади реформалары башлану | **4)** | 1991 ел |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

229. Вакыйгалар һәм шул вакыйгалар булган еллар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **ВАКЫЙГАЛАР** | | **ЕЛЛАР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | КПССның XX съезды | **1)** | 1956 ел |
| **Б)** | РФ Конституциясе кабул ителү | **2)** | 1961 ел |
| **В)** | Кешенең беренче тапкыр космоска очуы | **3)** | 1991 ел |
| | | **4)** | 1993 ел |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

230. Вакыйгалар һәм шул вакыйгалар булган еллар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **ВАКЫЙГАЛАР** | | **ЕЛЛАР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | җиргә шәхси милекчелекне бетерү | **1)** | 1906 ел |
| **Б)** | Яңа икътисад сәясәтенә (нэп) күчү | **2)** | 1917 ел |
| **В)** | П.А. Столыпинның аграр реформалары башлану | **3)** | 1921 ел |
| | | **4)** | 1928 ел |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

231. Вакыйгалар һәм эшчәнлекләре шул вакыйгалар белән бәйле ил җитәкчеләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **ВАКЫЙГАЛАР** | **ИЛ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ** |
| --- | --- |
| **А)** РФ Иҗтимагый палатасын төзү | **1)** Н.С. Хрущёв |
| **Б)** Беловеж килешүенә кул кую | **2)** Л.И. Брежнев |
| **В)** Хельсинки килешүләренә кул кую | **3)** Б.Н. Ельцин |
| | **4)** В.В. Путин |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

232. Совет хакимияте органнары һәм аларның җитәкчеләре арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **ХАКИМИЯТ ОРГАННАРЫ** | **ҖИТӘКЧЕЛӘР** |
| --- | --- |
| **А)** Халык Комиссарлары Советы | **1)** М.И. Калинин |
| **Б)** Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты | **2)** Н.И. Бухарин |
| **В)** Контрреволюция һәм саботаж белән көрәшү буенча Бөтенроссия гадәттән тыш Комиссиясе | **3)** Ф.Э. Дзержинский |
| | **4)** В.И. Ленин |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

233. Вакыйгалар һәм шул вакыйгалар булган еллар арасында тәңгәллек урнаштырыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **ВАКЫЙГАЛАР** | **ЕЛЛАР** |
| --- | --- |
| **А)** Варшава килешүе оешмасы төзелү | **1)** 1955 ел |
| **Б)** Кариб кризисы | **2)** 1962 ел |
| **В)** Европада Куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек буенча киңәшмәнең Ахыргы актына кул куелу | **3)** 1975 ел |
| | **4)** 1985 ел |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

234. Түбәндә санап кителгән тарихи эшлеклеләрнең кайсылары Гражданнар сугышында катнашкан? Исемлектән ике эшлеклене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** Р.И. Кондратенко

**2)** М.Н. Тухачевский

**3)** С.О. Макаров

**4)** А.И. Деникин

**5)** С.Ю. Витте

235. Түбәндә санап кителгән территорияләрнең кайсылары 1940 елда СССРга кушылган. Исемлектән ике территорияне сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** Азербайджан

**2)** Эстония

**3)** Польша

**4)** Латвия

**5)** Грузия

236. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсылары Гражданнар сугышы вакытында булган? Исемлектән ике вакыйганы сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** П.А. Столыпин үтерелү

**2)** Чехословакия корпусы фетнәсе

**3)** Германия белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнашу

**4)** Ирекләләр армиясе формалашу

**5)** СССР  барлыкка килү

237. Түбәндә санап кителгән сәяси партияләрнең кайсылары 1917 елның ноябре – 1918 елның мартында совет хөкүмәтенә кергәннәр? Исемлектән ике партияне сайлап

алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) кадетлар
2) большевиклар
3) сул эсерлар
4) октябристлар
5) анархистлар

238. Түбәндә санап кителгән сәяси эшлеклеләрнең кайсылары 1917 елда Вакытлы хөкүмәт белән җитәкчелек иткәннәр? Исемлектән ике эшлеклене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) Л.Г. Корнилов
2) А.Ф. Керенский
3) П.А. Столыпин
4) Г.Е. Львов
5) С.Ю. Витте

239. Түбәндә санап кителгән хәрби җитәкчеләрнең кайсылары Берлинга һөҗүм итү операциясе фронтлары белән идарә иткән? Исемлектән ике җитәкчене сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) К.К. Рокоссовский
2) А.М. Василевский
3) И.Д. Черняховский
4) И.С. Конев
5) Н.Ф. Ватутин

240. Түбәндә санап кителгән вакыйгаларның кайсылары 1917 елда булган? Исемлектән ике вакыйганы сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

1) СССР барлыкка килү


2) Николай II нең тәхеттән ваз кичүе

3) Кронштадтта морякларның большевикларга каршы восстаниесе

4) Җир турында  Декрет кабул ителү

5) «Князь Потёмкин-Таврический» броненосецында восстание

241 Схеманы карагыз һәм сорауга җавап  бирегез.




Схемада Кызыл Армиянең кем җитәкчелегендәге гаскәрләргә каршы хәрәкәтләре билгеләнгән?


1) А.В. Колчак

2) П.Н. Врангель

3) Н.Н. Юденич

4) П.Н. Краснов

242. Бөек Ватан сугышы чоры белән бәйле схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




Белгород шәһәренең нинди цифр белән тамгаланганын күрсәтегез.


**1)** 1

**2)** 2

**3)** 3

**4)** 4

243. Бөек Ватан сугышы чоры белән бәйле схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




«1» цифры белән тамгаланган кешеләр яшәү пунктының исемен күрсәтегез.


1) Калач

2) Прохоровка

3) Крюково

4) Дубосеково

244. Бөек Ватан сугышы чоры белән бәйле схеманы карагыз һәм биремне үтәгез.




1943 елда совет гаскәрләре тарафыннан азат ителгән шәһәрнең нинди номер белән тамгаланганын күрсәтегез.


**1)** 1

**2)** 2

**3)** 3

**4)** 4

245. Схеманы карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Фашист гаскәрләре тарафыннан басып алынмаган шәһәр нинди цифр белән тамгаланган?


1) 1

2) 2

**3)** 3

**4)** 4

246. Бөек Ватан сугышы чоры белән бәйле схеманы карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




“Тормыш юлы” үткәрелгән шәһәр  схемада нинди цифр белән тамгаланган?

**1)** 1

**2)** 2

**3)** 3

**4)** 4

247. Рәсемне карагыз һәм биремне үтәгез.




Әлеге плакатның ничәнче елда булган вакыйга уңае белән ясалуын күрсәтегез.

**1)** 1957 ел

**2)** 1961 ел

**3)** 1963 ел

**4)** 1969 ел

248. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Әлеге марка кайсы сугышның тәмамлануына  25 ел тулу уңае белән чыгарылган?

1) Мәскәү өчен сугыш
2) Сталинград сугышы
3) Берлин өчен сугыш
4) Кёнигсберг штурмы

249. 1920 -  1930 елларда идарә иткән партияләрнең хакимлек өчен эчке көрәшнең үзенчәлекләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага - охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын сайлап языгыз.

1) массакүләм мәгълүмат чараларында каршы якларның позицияләрен ирекле дискуссия рәвешендә тикшерү
2) оппозициядә катнашучыларны партия составыннан чыгару
3) ВКП(б) ҮК Политбюросының элеккеге әгъзаларын суд карары белән атып үтерү
4) И.В.Сталинның идарә итүче партия һәм ил белән хакимлек итүдә роле әкренләп үсүе

250. Олырак яшьтәге эшче заводта эшли иде. Губерна халык хуҗалыгы советы карары нигезендә бу завод ябылды, чөнки  ак армияләр илнең җитди чимал районнарын басып алдылар һәм заводка продукция җитештерү өчен чимал юк иде. Башта эшче очраклы эшләрдә эшләп йөрде, озакламый андый эшләр дә бетте. Шуннан соң ул өеннән кайбер шәхси әйберләрен алып, авылга азыкка алмаштырырга дип китте. Ләкин кире юлда эшче кайткан эшелонны азык-төлек отряды туктатты һәм ул алып кайткан ашамлыкларны каерып алды, эшче үзе көчкә-көчкә исән-сау өенә кайтып җитә алды.

1. Тасвирланган вакыйгаларның кайсы сугыш вакытында булуын күрсәтегез.

2. Шул чорда үз теләкләре белән шәһәрдән авылга үзләре ашар өчен яки сатар өчен азык-төлеккә барган  кешеләрне ничек дип атаганнар?

3. Ни өчен азык-төлек отряды солдатлары эшчедән аның  ризыгын тартып алганнар?

251. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Әлеге плакатны ясауга нинди вакыйга этәргеч ясаган?

1) Кырым сугышы

2) 1877 - 1878 еллардагы рус-төрек сугышы

**3)** рус - япон сугышы

**4)** Беренче бөтендөнья сугышы

252. Фронт линиясендә сугышучы хәрби часть солдатлары янына агитатор килде һәм аларга илдә революция булуы, патшаның бәреп төшерелүе, яңа хөкүмәт формалашуы турында хәбәр итте. Агитатор, Петроград Советы боерыгына нигезләнеп, солдатларның үзидарә органын сайларга тәкъдим итте. Бу органны сайларга каршы килгән офицерларның кораллары алынды.

1. Тасвирланган вакыйгаларның ничәнче елда булуын күрсәтегез.
2. Әлеге тасвирланган вакыйгаларның кайсы хөкүмәт вакытында булуын күрсәтегез.
3. Биремдә искә алынган приказның тарихка нинди исем белән керүен күрсәтегез.

253. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Әлеге кәгазь акчаның барлыкка килүе нинди вакыйга белән бәйле?

**1)** Г.Я. Сокольниковның финанс реформасы

**2)** А.В. Колчака хөкүмәтенең финанслар өлкәсендәге эшчәнлеге

**3)** Вакытлы хөкүмәтнең финанслар өлкәсендәге сәясәте

**4)** 1930 елларда Совет хөкүмәтенең  финанслар өлкәсендәге сәясәте

254. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Әлеге плакат ясалган...

1) Беренче рус революциясе чорында
2) 1917 елда
3) Гражданнар сугышы чорында
4) 1920–1930 елларда

255. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Әлеге марка ничәнче елда чыккан?

**1)** 1957 елда

**2)** 1961 елда

**3)** 1967 елда

**4)** 1971 елда

256. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Әлеге плакат ясалган...

1) 1917 елның март-октябрь чорында
2) Гражданнар сугышы чорында
3) Нэп чорында
4) 1930 елларда

257. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*Корыч эретү (млн тонна)*

| **Илләр** | **1913 ел** | **1937 ел** | **1956 ел** |
|---|---|---|---|
| СССР (Россия) | 4,2 | 17,7 | 48,7 |
| АКШ | 31,8 | 51,4 | 104,5 |
| Англия | 7,8 | 13,2 | 21 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**А)** 1913 —1956 елларда корыч эретүнең күләмен иң күп арттырган

**Б)** 1937 елда корычны иң күп эреткән

**В)** Англия 1956 елда 1913 елга караганда корыч җитештерүне арттырган

**1)** СССР

**2)** өчтән күбрәк тапкыр

**3)** АКШ

**4)** Англия

**5)** өчтән кимрәк тапкыр

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

258. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*Дөньяда сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы продукцияләренең аерым төрләрен җитештерү*

| | **1960 ел** | **1970 ел** | **1980 ел** |
|---|---|---|---|
| Йон тукымалар, млрд кв. м | 2,9 | 3,3 | 3,6 |
| Шикәр чөгендере (фабрикада), млн т | 184 | 224 | 264 |
| Бәрәңге, млн т | 290 | 312 | 250 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1960—1970 елларда ... җитештерү иң аз процентта үскән

**Б)** 1960 — 1980 елларда... җитештерү иң күп процент үскән

**В)** 1970—1870 елларда ... җитештерү иң күп процент үскән

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** бәрәңге

**2)** йон тукымалар

**3)** таблицада күрсәтелгән барлык төр продукцияләр

**4)** таблицада күрсәтелгән кайбер төр продукцияләр

**5)** шикәр чөгендере

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

259. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*1922—1931 елларда сәнәгатьтә эшче көчләре саны динамикасы*

| **Күрсәткечләр** | **Еллар** | | |
|---|---|---|---|
| | **1922 ел** | **1928 ел** | **1931 ел** |
| «А» төркемендәге предприятиеләрдә эшчеләр саны (мең кеше) | 688,4 | 1377,5 | 2019,0 |
| «Б» төркемендәге предприятиеләрдә эшчеләр саны (мең кеше) | 407,8 | 1221,1 | 1385,9 |
| «А» төркемендәге предприятиеләрдә эшчеләр саны динамикасы (узган елга карата % да) | 91,3 | 106,8 | 129,0 |
| «Б» төркемендәге предприятиеләрдә эшчеләр саны динамикасы (узган елга карата % да) | 94,4 | 110,7 | 107,0 |

| **ФИКЕР БАШЫ** | | **ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР** | |
|---|---|---|---|
| **А)** | «А» төркемендәге предприятиеләрдә эшчеләр саны | **1)** | таблицада күрсәтелгән барлык елларда «Б» төркемендәге предприятиеләрдәге эшчеләр санынннан артыграк була |
| **Б)** | «А» төркемендәге предприятиеләрдә эшчеләр саны арту (% да) узган ел белән чагыштырганда ... күзәтелә. | **2)** | 1922 елда |
| **В)** | «Б» төркемендәге предприятиеләрдә эшчеләр саны кимү (% да) узган ел белән чагыштырганда ... күзәтелә. | **3)** | 1928 елда |
| | | **4)** | таблицада күрсәтелгән кайбер елларда «Б» төркемендәге предприятиеләрдәге эшчеләр санынннан артыграк була |

| | **5)** | 1931 елда |
|---|---|---|

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

260. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*СССРның аерым социалистик илләр белән тышкы сәүдә әйләнеше (млн. сум)*

| **Илләр** | **1970 ел** | **1975 ел** | **1980 ел** |
|---|---|---|---|
| Болгария | 1 816 | 3 991 | 7 099 |
| Венгрия | 1 480 | 3 274 | 5 738 |
| ГДР | 3 295 | 5 623 | 9 200 |

| **ФИКЕР БАШЫ** | **ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР** |
|---|---|
| **А)** СССРның иң күп тышкы сәүдә әйләнеше... булган | **1)** Болгария белән |
| **Б)** СССРның Болгария белән тышкы сәүдә әйләнеше 1980 елда1970 ел белән чагыштырганда ... арткан | **2)** Венгрия белән |
| **В)** СССРның иң аз тышкы сәүдә әйләнеше... булган | **3)** өчтән кимрәк тапкыр |
| | **4)** өчтән күбрәк тапкыр |
| | **5)** ГДР белән |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

261. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*СССРның аерым капиталистик илләр белән тышкы сәүдә әйләнеше (млн. сум)*

| **Илләр** | **1981 ел** | **1983 ел** | **1985 ел** |
|---|---|---|---|
| ФРГ | 6 009 | 7 022 | 7 086 |
| Франция | 4 189 | 4 150 | 3 778 |
| АКШ | 1 845 | 1 900 | 2 702 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** СССРның иң күп тышкы сәүдә әйләнеше... булган

**Б)** СССРның таблицада күрсәтелгән барлык илләр белән тышкы сәүдә әйләнеше таблицада күрсәтелгән узган еллар белән чагыштырганда...

**В)** СССРның иң аз тышкы сәүдә әйләнеше... булган

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** АКШ белән

**2)** һәрвакыт артмаган

**3)** ФРГ белән

**4)** бары тик арткан

**5)** Франция белән

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

262. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*Дөньяда кайбер сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерү*

| | **1960 ел** | **1970 ел** | **1980 ел** |
|---|---|---|---|
| Электроэнергия, трлн кВт-ч | 2,4 | 5,1 | 8,3 |
| Киҗе-мамык (сүскә күчереп санаганда), млн т | 9,9 | 12,3 | 13,8 |
| Күмер (сәүдә), млн т | 2 574 | 2 924 | 3746 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1960—1970 елларда иң күп процент мөнәсәбәтендә ... җитештерү үскән

**Б)** Әлеге таблица

**В)** 1970—1980 елларда иң аз процент мөнәсәбәтендә ... җитештерү үскән

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** киҗе-мамык

**2)** 1980 елда АКШ башка илләргә караганда электроэнергия җитештерүдә өстенрәк булган дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә

**3)** электроэнергия

**4)** 1980 елда АКШ башка илләргә карагандa электроэнергия җитештерүдә өстенрәк булган дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирми

**5)** күмер

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

263. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*1913-1939 елларда халык составы үзгәрү (гомуми халык составына карата процентларда)*

| **Халык категориясе** | **1913 ел** | **1928 ел** | **1939 ел** |
|---|---|---|---|
| Эшчеләр һәм хезмәткәрләр | 17,0 | 17,6 | 50,2 |
| Колхоз крестьяннары һәм кооперативлашкан һөнәрчеләр | 0 | 2,9 | 47,2 |
| Аерым хуҗалыклы крестьяннар һәм кооперативлашмаган һөнәрчеләр | 66,7 | 74,9 | 2,6 |
| Буржуазия, алпавытлар, сәүдәгәрләр һәм кулаклар | 16,3 | 4,6 | 0 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** 1913—1939 елларда ... саны арткан

**Б)** Таблицада күрсәтелгән узган елга караганда эшчеләрнең саны сизелерлек арту ... күзәтелә

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** буржуазиянең, алпавытларның, сәүдәгәрләрнең һәм кулакларның

**2)** колхоз крестьяннарының һәм кооперативлашкан һөнәрчеләрнең

**3)** 1928 елда

**4)** 1939 елда

**В)** 1939 елда .... категориясе бетерелгән

**5)** аерым хуҗалыклы крестьяннарның һәм кооперативлашмаган һөнәрчеләрнең

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

264. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*СССРда белгечләр саны (мең кеше)*

| **Белгечләр** | **1926 ел** | **1959 ел** |
|---|---|---|
| Предприятие, төзелеш, совхоз, колхоз, администрация оешмалары һәм башка учреждениеләр җитәкчеләре | 365 | 2 223 |
| Инженерлар, техниклар һәм агрономнар | 267 | 4 683 |
| Укытучылар һәм башка мәдәният, мәгариф өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр | 486 | 3 276 |
| Врачлар һәм кече медицина персоналы | 199 | 1 702 |
| Фән хезмәткәрләре | 14 | 316 |

**<u>ФИКЕР БАШЫ</u>**

**А)** 1929—1959 елларда ... саны 20 дән күбрәк тапкыр арткан

**Б)** 1926 елда җитәкчеләрнең саны ... саныннан азрак булган

**В)** Белгечләрнең гомуми саны ... 12 миллионнан арткан

**<u>ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР</u>**

**1)** врачларның һәм кече медицина персоналының

**2)** укытучыларның һәм башка мәдәният, мәгариф өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең

**3)** 1926 елда

**4)** 1959 елда

**5)** фән хезмәткәрләренең

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

265. Статистик таблица мәгълүматлары ярдәмендә түбәндә китерелгән фикерләрне, аларның баштагы җөмләләрен ахыргы җөмләләре белән туры китереп, тәмамлагыз.

*СССР да белемле халык саны (процентларда).*

| **Еллар** | **Ирләр** | **Хатын-кызлар** |
|---|---|---|
| **Шәһәр халкы** | | |
| 1926 | 88,0 | 73,9 |
| 1939 | 97,6 | 91,0 |
| 1959 | 99,5 | 98,1 |
| **Авыл халкы** | | |
| 1926 | 67,3 | 35,4 |
| 1939 | 93,7 | 79,2 |
| 1959 | 99,1 | 97,5 |

**ФИКЕР БАШЫ**

**А)** СССРда авылда яшәүче белемле хатын-кызларның проценты ... 90% тан арткан

**Б)** Белемле хатын-кызларның проценты белемле ирләрнең процентыннан ... сизелерлек аерылып торган

**В)** ... авылда яшәүче якынча һәр ирнең өченчесе белемсез булган

**ФИКЕРНЕ ТӘМАМЛАУ ӨЧЕН ВАРИАНТЛАР**

**1)** 1959 елда

**2)** шәһәрдә

**3)** авылда

**4)** 1926 елда

**5)** 1939 елда

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

266. Төшеп калган сүзне языгыз.

1989—1990 елларда Көнчыгыш Европа илләрендә коммунистик режимның җимерелүенә китергән массакүләм халык күтәрелешләре _______________ революциясе дигән исем алдылар.

267. Алдагы аңлатмага туры килгән терминны языгыз.
1922 елда Совет Россиясендә Г.Я. Сокольниковның финанс реформасы үткәрү вакытында кертелгән һәм стабиль акча системасын тергезергә ярдәм иткән акча берәмлеге.

268. Төшеп калган сүзне языгыз.
1989 елның маенда Мәскәүдә СССРның ______________ I Съезды эшен башлады.

269. Төшеп калган сүзне языгыз.
2013 елның 5 августында Атмосферада, ______________ киңлектә һәм су астында атом-төш коралларын сынауны тыю турында килешүгә кул куелуга 50 ел тулды.

270. Төшеп калган сүзне языгыз.
1943 елның август–сентябрендә дошман тарафыннан вакытлыча басып алынган совет территорияләрендә Совет партизаннарының тимер юлы коммуникацияләрен бозу буенча операциясе “__________________ сугышы” дигән исем алды.

271. Төшеп калган сүзне языгыз.
1977 елда кабул ителгән СССР Конституциясе “_______________ социализм Конституциясе” дигән исем белән тарихка керде.

272. СССР җитәкчесе белән интервьюдан өзек укыгыз һәм шул җитәкчене күрсәтегез.
«Миңа 26 апрельдә иртәнге сәгать 5тә шалтыратып, коточкыч авария һәм янгын булуы, ләкин реакторның төзек калуы турында хәбәр иттеләр.
Авариянең беренче сәгатьләрендә, хәтта авария булып, берничә тәүлек үткәннән соң да реакторның шартлавы һәм атмосферага гигант атом-төш чыгармалары ташлануы аңнарга барып җитмәгән иде әле. Инде 27 апрельдә үрнәк операция үткәрелде: 3 сәгать эчендә Припяти шәһәренең бөтен кешесе – 47 мең кеше эвакуацияләнде. Ә майның беренче көннәрендә станциядән 30 км зонадагы барлык яшәүчеләр – 116 мең кеше, уннарча торак пунктлары эвакуацияләнде.
Минем уйлавымча, миңа мөмкин булган кадәр дөрес мәгълүмат житкерделәр. Беренче

вакытта хәтта иң яхшы белгечләр дә һәлакәтнең шул дәрәҗәдә җитди булуын аңламадылар».

1) Н.С. Хрущёв
2) М.С. Горбачёв
3) Л.И. Брежнев
4) Ю.В. Андропов

273. Сәясәт эшлеклесенең истәлекләреннән өзек укыгыз һәм тасвирланган ситуацияләрнең ничәнче елда булуын күрсәтегез.
«25 декабрьнең чәршәмбе кичендә мин телевидениедән ватандашларга мөрәҗәгать белән чыктым һәм СССР Президенты урыныннан китүем турында игълан ясадым. Бу чыгышны тулысынча ике газета гына бастырды. Менә ул мөрәҗәгать. «Кадерле ватандашлар! Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге барлыкка килү белән бәйле ситуациядә мин СССР Президенты буларак эшчәнлегемне төгәллим. Бу карарны принципиаль сәбәпләр аркасында кабул итәм. Мин халыкларның мөстәкыйльлеге, бәйсезлеге, республикаларның суверенитеты өчен тырыштым. Шул ук вакытта союз дәүләтләрен саклап калу, илнең бөтенлеге ягында идем. Ләкин вакыйгалар башка юнәлештә китте. Илнең таркалу, дәүләтләрнең бер-берсеннән аерылу линиясе өстенлек алды. Мин бу хәл белән килешә алмыйм».

1) 1985 елда
2) 1991 елда
3) 1996 елда
4) 1999 елда

274. Рәсемне карагыз һәм сорауга җавап бирегез.




Әлеге медаль кайчан булган вакыйга уңае белән чыгарылган?

**1)** 1944 елның июнендә

**2)** 1944 елның октябрендә

**3)** 1945 елның февралендә

**4)** 1945 елның маенда

275. Сурәтне карагыз һәм биремне үтәгез.



Әлеге фотография төшерелгән елны күрсәтегез.

1) 1985 ел

2) 1989 ел

3) 1991 ел

4) 1998 ел

276. 1953—1964 һәм 1985—1991 елларда СССРның иҗтимагый-сәяси үсешенең үзенчәлекле билгеләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага - охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын сайлап языгыз.

1) илдә оппозицион сәяси партияләр эшчәнлеге

2) ГУЛАГта әсир булган кешеләрнең тормышы турында әдәби әсәрләр бастырылу

3) яңа югары вәкаләтле дәүләт хакимияте органнары төзелү

4) гамәлдәге Конституцияләр буенча СССР социалистик ил булып тора

277. 1920 — 1922 елларда Совет Россиясенең һәм 1923 — 1929 елларда СССРның халыкара хәлен чагыштырыгыз. Беренче баганага - охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын сайлап языгыз.

1) Германия белән икътисади хезмәттәшлек
2) Совет дәүләтенең “танылу вакыты”
3) АКШ белән дипломатик мөнәсәбәтләр булмау
4) Ерак Көнчыгышта япон гаскәрләренең интервенциясе (Ерак Көнчыгыш республикасы территориясенә)

278. Икенче бөтендөнья сугышының ике чорын чагыштырыгыз: 1941 елның 22 июне — 1942 елның 18 ноябре һәм 1942 елның 19 ноябре — 1943 елның ахыры. Беренче баганага - охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын сайлап языгыз.

1) Сталинград янындагы сугышлар
2) СССР, Англия һәм АКШ җитәкчеләренең (“Зур өчлек”) халыкара конференциясе үткәрелү
3) фашист Германиясенең «Блицкриг» дип аталган яшен тизлегендәге сугыш планын тормышка ашыруы
4) Гитлерга каршы коалиция булу

279. СССРның 1953—1964 һәм 1985—1991 еллардагы иҗтимагый-сәяси үсеш үзенчәлекләрен чагыштырыгыз. Беренче баганага - охшашлыкларның, икенче баганага аерымлыкларның тәртип номерларын сайлап языгыз.

1) сәяси репрессия корбаннарын реабилитацияләү
2) СССР составындагы союздаш республикаларның суверениты турында декларация кабул ителү
3) СССР Президенты вазыйфасы булу

**4)** хөкүмәткә каршы ачык протест акцияләре үткәрелү

280. Тарихи документтан өзек укыгыз һәм текстта тасвирланган вакыйгалар буенча СССРда кем җитәкче булуын күрсәтегез.

«Үзгәртеп кору – бу торгынлык процессларын җиңү, каршылык механизмнарын җимерү, совет җәмгыятенең социаль-сәяси үсешен тизләтә торган ышанычлы һәм эффектив механизм төзү. Илебезнең төп нияте – фән-техника казанышларын планлы икътисад белән кушу һәм социализмның бөтен потенциалын хәрәкәткә китерү».

281. АКШ президенты Дж. Кеннединың Н.С. Хрущёвка хатыннан өзек укыгыз һәм нинди вакыйга турында сүз баруын әйтегез.

“Мин ачыктан-ачык белдерәм, әгәр Кубада билгеле бер вакыйгалар булса, Кушма Штатлары үзенең һәм союзникларының куркынычсызлыгы өчен барысын да эшләячәк. Сезнең хөкүмәт бу кризисны киңәйтүгә һәм тирәнгә җибәрүгә юнәлдерелгән һәртөрле хәрәкәтләрдән тоткарланып торыр дип ышанам”.

282. Мәдәният эшлеклеләре һәм аларның иҗат өлкәләре арасында тәңгәллек табыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **МӘДӘНИЯТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ** | **ИҖАТ ӨЛКӘЛӘРЕ** |
|---|---|
| **А)** Г.В. Александров | **1)** кинематограф |
| **Б)** О.Э. Мандельштам | **2)** фән |
| **В)** Н.И. Вавилов | **3)** театр |
| | **4)** әдәбият |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

283. XX гасыр мәдәният эшлеклеләре һәм аларның иҗат өлкәләре арасында тәңгәллек табыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры

килүче элементны табыгыз.

| **<u>МӘДӘНИЯТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ</u>** | **<u>ИҖАТ ӨЛКӘЛӘРЕ</u>** |
|---|---|
| **А)** Е.А. Евтушенко | **1)** драма театры |
| **Б)** О.П. Табаков | **2)** рәсем сәнгате |
| **В)** Г.С. Уланова | **3)** әдәбият |
| | **4)** балет |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

284. Мәдәният эшлеклеләре һәм аларның иҗат өлкәләре арасында тәңгәллек табыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **<u>МӘДӘНИЯТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ</u>** | **<u>ИҖАТ ӨЛКӘЛӘРЕ</u>** |
|---|---|
| **А)** С.Ф. Бондарчук | **1)** поэзия |
| **Б)** А.А. Вознесенский | **2)** кино |
| **В)** Д.Д. Шостакович | **3)** рәсем сәнгате |
| | **4)** музыка |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

285. Түбәндә санап кителгән шәхесләрнең кайсысы космонавт буларак билгеле. Исемлектән ике космонавтны сайлап алыгыз һәм аларга туры килгән цифрларны язып куегыз.

**1)** С.П. Королёв

**2)** А.А. Леонов

**3)** В.В. Терешкова

**4)** А.Н. Туполев

**5)** И.В. Курчатов

286. Мәдәният эшлеклеләре һәм аларның иҗат өлкәләре арасында тәңгәллек табыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **МӘДӘНИЯТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ** | **ИҖАТ ӨЛКӘЛӘРЕ** |
|---|---|
| **А)** А.Т. Твардовский | **1)** театр |
| **Б)** О.П. Табаков | **2)** әдәбият |
| **В)** М.Л. Ростропович | **3)** скульптура |
| | **4)** музыка |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

287. Дәүләт башлыклары һәм алар идарә иткән чорда эзәрлекләүгә дучар булган мәдәният эшлеклеләре арасында тәңгәллек табыгыз: икенче баганадан беренче баганадагы һәр элементка туры килүче элементны табыгыз.

| **ДӘҮЛӘТ БАШЛЫКЛАРЫ** | **МӘДӘНИЯТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ** |
|---|---|
| **А)** И.В. Сталин | **1)** И.А. Бродский |
| **Б)** Н.С. Хрущёв | **2)** М.М. Зощенко |
| **В)** Л.И. Брежнев | **3)** Б.Л. Пастернак |
| | **4)** С.В. Михалков |

Җаваплар рәтендә сайлап алынган саннарны тиешле хәрефләр астына языгыз.

288. Истәлекләрдән өзек укыгыз һәм авторының фамилиясен языгыз.
“Берничә минуттан гайрәтле космик корабле мине Галәмнең чиксез киңлекләренә алып менеп китәчәк. Старт алдыннан берничә минут кала нәрсә әйтергә була? Минем бөтен тормышым бер гүзәл мизгел кебек. Бөтен яшәгәнем, эшләгәнем шушы минутлар өчен <…> Беренче булып космоста булу – моннан да зуррак хыял булырга мөмкинме?”

289. Федераль Җыелышка мөрәҗәгатьнамәне укыгыз һәм шуның белән чыгыш ясаган Президентның фамилиясен языгыз.

“Хәзер Россия җитештерүдә озакка сузылган артталыкны тулысынча җиңеп кенә калмыйча, дөньядагы ун иң көчле икътисадлар рәтенә керде. 2000 нче елдан халыкның реаль керемнәре ике тапкыр артты. Ел ярым элек без приоритетлы милли проектларны тормышка ашыра башладык, аларның төп максаты – кешегә инвестицияләү, тормыш дәрәҗәсен күтәрү...”

290. Сезгә “Ил белән Н.С.Хрущев идарә иткән чорда СССРның социаль-икътисади үсеше” дигән темага киңәйтелгән җавап әзерләргә тәкъдим ителә. Бу теманы яктырту өчен план төзегез. План кимендә өч пункттан торырга тиеш. Сайлап алынган ике пунктның эчтәлегенә кыскача аңлатма языгыз. Аңлатмалы план Н.С. Хрущев идарә иткән чорда СССРның социаль-икътисади үсеше белән бәйле төп вакыйгаларны яктыртырга тиеш.

*Әгәр Сезгә әлеге теманы тулысынча ачарга ярдәм итәчәк планны төзү авырлык тудыра икән, Сез әлеге теманың бер әһәмиятле соравын (бүлеген, юнәлешен, проблемасын) сайлый аласыз.*

*Сайлаган сорау (бүлек, юнәлеш, проблема) буенча планның исемен языгыз һәм, пунктларның санына һәм аңлатмаларна куелган таләпләрне үтәп, эчтәлекне ачарга мөмкинлек биргән план төзегез.*

291. Сезгә “Бөек Ватан сугышы барышында тамырдан борылыш” дигән темага киңәйтелгән җавап әзерләргә тәкъдим ителә. Бу теманы яктырту өчен план төзегез. План кимендә өч пункттан торырга тиеш. Сайлап алынган ике пунктның эчтәлегенә кыскача аңлатма языгыз. Аңлатмалы план тема белән бәйле төп вакыйгаларны яктыртырга тиеш.

*Әгәр Сезгә әлеге теманы тулысынча ачарга ярдәм итәчәк планны төзү авырлык тудыра икән, Сез әлеге теманың бер әһәмиятле соравын (бүлеген, юнәлешен, проблемасын) сайлый аласыз.*

*Сайлаган сорау (бүлек, юнәлеш, проблема) буенча планның исемен языгыз һәм, пунктларның санына һәм аңлатмаларна куелган таләпләрне үтәп, эчтәлекне ачарга мөмкинлек биргән план төзегез.*

292. Язгы чәчү алдыннан крестьяннар, урындагы һәм үзәк хакимиятнең көчсезлегеннән файдаланып, алпавытларның җирен һәм мөлкәтен бүлә башладылар. Ә көз көне алпавыт җирләрен законлы рәвештә бүләргә мөмкин дигән Советлар Съездының декреты чыкты.

1. Тасвирланган вакыйгаларның ничәнче елда булуын күрсәтегез.
2. Ни өчен урындагы һәм үзәк хакимиятнең крестьяннарга җирләрне бүләргә мөмкинлек тудырган көчсезләнүе күзәтелгән?

Алпавыт җирләрен законлы рәвештә бүләргә мөмкинлек биргән документ ничек дип аталган?

293. Беренче бишьеллык төзелешләренә кимендә ике мисал китерегез.

294. Сезгә “Совет Россиясенең Гражданнар сугышы вакытындагы эчке сәясәте. “Хәрби коммунизм” эпохасы” дигән темага киңәйтелгән җавап әзерләргә тәкъдим ителә. Бу теманы яктырту өчен план төзегез. План кимендә өч пункттан торырга тиеш. Сайлап алынган ике пунктның эчтәлегенә кыскача аңлатма языгыз. Аңлатмалы план Совет Россиясенең Гражданнар сугышы вакытындаг эчке сәясәте һәм “Хәрби коммунизм” эпохасы белән бәйле төп вакыйгаларны яктыртырга тиеш.

*Әгәр Сезгә әлеге теманы тулысынча ачарга ярдәм итәчәк планны төзү авырлык тудыра икән, Сез әлеге теманың бер әһәмиятле соравын (бүлеген, юнәлешен, проблемасын) сайлый аласыз.*

*Сайлаган сорау (бүлек, юнәлеш, проблема) буенча планның исемен языгыз һәм, пунктларның санына һәм аңлатмаларна куелган таләпләрне үтәп, эчтәлекне ачарга мөмкинлек биргән план төзегез.*

295. Совет галиме-генетикны күрсәтегез.

1) О.Ю. Шмидт

2) М.А. Шолохов

3) С.П. Королёв

4) Н.И. Вавилов

296. Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да СССР тарихының 1985-1991 елларында булган вакыйгалар, күренешләр белән бәйле.
1) «*үзгәртеп кору*»; 2) *альтернатив нигездә сайлаулар;* 3) *федераль төбәкләр;* 4) *референдум;* 5) «*парад суверенитетлар парады*».
Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

297. Сезгә "Россия Федерациясенең базар икътисадына күчүе (1990 елларның беренче яртысы)" дигән темага киңәйтелгән җавап әзерләргә тәкъдим ителә. Бу теманы яктырту өчен план төзегез. План кимендә өч пункттан торырга тиеш. Сайлап алынган ике пунктның эчтәлегенә кыскача аңлатма языгыз. Аңлатмалы план 1990 елларның беренче яртысында Россия Федерациясендә базар икътисадына күчү белән бәйле төп вакыйгаларны яктыртырга тиеш.
*Әгәр Сезгә әлеге теманы тулысынча ачарга ярдәм итәчәк планны төзү авырлык тудыра икән, Сез әлеге теманың бер әһәмиятле соравын (бүлеген, юнәлешен, проблемасын) сайлый аласыз.*
*Сайлаган сорау (бүлек, юнәлеш, проблема) буенча планның исемен языгыз һәм, пунктларның санына һәм аңлатмаларна куелган таләпләрне үтәп, эчтәлекне ачарга мөмкинлек биргән план төзегез.*

298. Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да СССР тарихының 1953-1964 елларында булган вакыйгалар, күренешләр белән бәйле.

1) *«җепшеклек»;* 2) *Берлин стенасы;* 3) *совнархозлар;* 4) *Хельсинки процессы;* 5) *партиягә каршы төркем.*

Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

299. Аерым уртаклыклар булуга карамастан, 1953-1964 елларда СССРда крестьяннарның хәле 1945- 1953 елларга караганда сизелерлек үзгәрде дигән фикер яши. Шушы үзгәрешләрнең булуын исбатлаган кимендә ике фактка мисал китерегез.

300. Сезгә "Россиядә Совет хөкүмәте урнашу" дигән темага киңәйтелгән җавап әзерләргә тәкъдим ителә. Бу теманы яктырту өчен план төзегез. План кимендә өч пункттан торырга тиеш. Сайлап алынган ике пунктның эчтәлегенә кыскача аңлатма языгыз. Аңлатмалы план Россиядә Совет хөкүмәте урнашу белән бәйле төп вакыйгаларны яктыртырга тиеш.

*Әгәр Сезгә әлеге теманы тулысынча ачарга ярдәм итәчәк планны төзү авырлык тудыра икән, Сез әлеге теманың бер әһәмиятле соравын (бүлеген, юнәлешен, проблемасын) сайлый аласыз.*

*Сайлаган сорау (бүлек, юнәлеш, проблема) буенча планның исемен языгыз һәм, пунктларның санына һәм аңлатмаларна куелган таләпләрне үтәп, эчтәлекне ачарга мөмкинлек биргән план төзегез.*

301. Крестьян кулаклыкта гаепләнүдән куркып колхозга керергә мәҗбүр булды. Ләкин озакламый дәүләт башлыгының "Уңышлардан баш әйләнү" дигән мәкаләсе басылып чыкты. Бу мәкалә басылганнан соң ВКП(б) ҮК шундый ук эчтәлекле карары чыкты һәм крестьян, дәүләт сәясәтендәге үзгәрешләрдән файдаланып, вакытлыча колхоздан чыга алды.

1. Текстта искә алынган мәкаләнең авторы буларак дәүләт башлыгын күрсәтегез.
2. Әлеге мәкалә чыккан елны күрсәтегез.

Әлеге мәкалә чыгуның сәбәбе нинди булган?

302. Сезгә “1953- 1964 елларда Россиянең тышкы сәясәте” дигән темага киңәйтелгән җавап әзерләргә тәкъдим ителә. Бу теманы яктырту өчен план төзегез. План кимендә өч пункттан торырга тиеш. Сайлап алынган ике пунктның эчтәлегенә кыскача аңлатма языгыз. Аңлатмалы план 1953- 1964 елларда Россиянең тышкы сәясәте белән бәйле төп вакыйгаларны яктыртырга тиеш.

*Әгәр Сезгә әлеге теманы тулысынча ачарга ярдәм итәчәк планны төзү авырлык тудыра икән, Сез әлеге теманың бер әһәмиятле соравын (бүлеген, юнәлешен, проблемасын) сайлый аласыз.*

*Сайлаган сорау (бүлек, юнәлеш, проблема) буенча планның исемен языгыз һәм, пунктларның санына һәм аңлатмаларна куелган таләпләрне үтәп, эчтәлекне ачарга мөмкинлек биргән план төзегез.*

303. Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да Бөек Ватан сугышы елларында булган вакыйгалар, күренешләр белән бәйле.

1) *«Барбаросса» планы;* 2) *«Ост планы»;* 3) *ленд-лиз;* 4) *«Маршалл планы»,* 5) *блицкриг.*

Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

304. Сезгә “Россиянең таркалуы” дигән темага киңәйтелгән җавап әзерләргә тәкъдим ителә. Бу теманы яктырту өчен план төзегез. План кимендә өч пункттан торырга тиеш. Сайлап алынган ике пунктның эчтәлегенә кыскача аңлатма языгыз. Аңлатмалы план Россиянең таркалуы белән бәйле төп вакыйгаларны яктыртырга тиеш.

*Әгәр Сезгә әлеге теманы тулысынча ачарга ярдәм итәчәк планны төзү авырлык тудыра икән, Сез әлеге теманың бер әһәмиятле соравын (бүлеген, юнәлешен, проблемасын) сайлый аласыз.*

*Сайлаган сорау (бүлек, юнәлеш, проблема) буенча планның исемен языгыз һәм, пунктларның санына һәм аңлатмаларна куелган таләпләрне үтәп, эчтәлекне ачарга мөмкинлек биргән план төзегез.*


305. Түбәндә терминнар исемлеге (аббревиатуралар) бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да 1945- 1953 елларда булган вакыйгалар, күренешләр белән бәйле.
1) *ЮНЕСКО;* 2) *БМО;* 3) *СЭВ;* 4) *НАТО;* 5) *ГКЧП.*
Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

306. Советлар Союзының 1920 нче һәм 1930 нчы еллардагы сәясәте бик нык аерылган. Шул ук вакытта уртаклыклар да булган. Шул уртаклыкларны раслый торган кимендә ике фактка мисал китерегез.


307. Түбәндә терминнар исемлеге бирелгән. Берсеннән кала, аларның барысы да 1953-1964 елларда булган вакыйгалар, күренешләр белән бәйле.
1) *Кариб кризисы;* 2) *Варшава килешүе;* 3) *Венгер кризисы;* 4) «*Прага язы»;* 5) *Берлин стенасы.*
Әлеге рәттән «төшереп калдырылырга» тиешле терминның тәртип номерын табыгыз һәм языгыз.

308 . Советлар Союзының 1945- 1953 нче һәм 1953- 1964 нче еллардагы тышкы сәясәте бик нык аерылган. Шул аерымлыкларны раслый торган кимендә ике фактка мисал китерегез.

309. Схемада төшеп калган союздаш республиканың исемен языгыз.



310. Схемада төшеп калган союздаш республиканың исемен – аббревиатураны языгыз.





311. Схемада төшеп калган фамилияне языгыз.




312. Схемада төшеп калган фамилияне языгыз.



313. Схемада төшеп калган сүзне языгыз.




314. Кызыл армия большевиклар тарафыннан яңа типтагы армия буларак төзелгән. Ләкин Гражданнар сугышы вакытында ук ул революциягә кадәрге иске армиянең күп үзенчәлекле билгеләрен кире алган. Әлеге фактны раслый торган кимендә ике фактка мисал китерегез.

315. СССР гражданнары арасында мәзәк таралган булган: «Коммунизм көткән идек, олимпиада булды".

1. Әлеге мәзәк таралу белән турыдан-туры бәйле елны күрсәтегез.
2. Әлеге чордагы дәүләт башлыгын күрсәтегез.
3. Мәзәкнең мәгънәсен аңлатыгыз.

316. 1950 еллар уртасында Сталин үлгәннән соң илдә сәяси режимның йомшарып китүе сизелде һәм ул совет җәмгыятенең бөтен тормышында чагылды. “Җылыну” халыкара мөнәсәбәтләргә дә керде.

Үткән чор белән чагыштырганда “җепшеклек” чорында СССРның тышкы сәясәтендә нинди үзгәрешләр булган?

Шул үзгәрешләрне исбатлый торган кимендә ике вакыйганы мисал итеп китерегез.

317. Икенче Бөтендөнья сугышы һәм Бөек Ватан сугышы чорларында халыкара мөнәсәбәтләрнең бер үзенчәлекле билгесе булып Гитлерга каршы коалициядә булган илләрнең даими очрашулар үткәрүе тора. 1943 елның ноябрь-декабрендә Тегеранда “Зур өчлек”кә кергән илләрнең очрашуы булды.

1943 елда Тегеранда үткәрелгән халыкара конференциядә нинди мәсьәләләр каралган? Кимендә өч мәсьәләне атагыз.

Икенче Бөтендөнья сугышы һәм Бөек Ватан сугышы чорларында СССР, Бөекбритания һәм АКШ башлыкларының башка халыкара конференцияләренә мисаллар китерегез. Үткәрелү даталарын күрсәтегез.

318. 1917 елның февралендә Россиядә монархияне бетерүгә һәм ике хакимият урнашуга китергән революция булды.

Шул ук вакытта уртаклыклар да булган. Февраль революциясенең сәбәпләре нинди? Кимендә ике сәбәпне күрсәтегез.

Февраль революциясенең беренче көннәрендә барлыкка килгән ике яңа хакимият органының исемнәрен атагыз.